**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 гыйнвар № 26

г. Казань

Татарстан Республикасында мотор ягулыгы сыйфатына экологик таләпләр турында

«Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 ел, 4 май, ФЗ-96 нчы һәм «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 ел, 10 гыйнвар, ФЗ-7 нче федераль законнарны, 2009 ел, 15 гыйнвар, ТРЗ-5 нче Татарстан Республикасы Законы белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Экология кодексын үтәү йөзеннән, автомобиль транспортының әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын киметү һәм автомобильләргә ягулык салу станцияләре тарафыннан судно һәм мич ягулыгын сатуга юл куймауга юнәлдерелгән чаралар күрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елның 1 февраленнән:

Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче автомобильләргә ягулык салу станцияләрендә Таможня берлегенең «Автомобиль һәм авиация бензинына, дизель һәм судно ягулыгына, реактив двигательләр өчен ягулыкка һәм мазутка таләпләр турында» (ТР ТС 013/2011) техник регламентының К5 экологик классы таләпләренә җавап бирүче мотор ягулыгы (автомобиль бензины һәм дизель ягулыгы), автомобиль транспорты чараларына майлар, майлау матдәләре, махсус сыеклыклар, запас өлешләр кабул итү, саклау һәм сатуны гамәлгә ашырырга, шулай ук транспорт чаралары хуҗаларына һәм пассажирларына хезмәтләр күрсәтергә;

Татарстан Республикасының нефть продуктлары белән тәэмин итү предприятиеләренә автомобильләргә ягулык салу станцияләрендә ягулык салу колонкалары аша судно һәм мич ягулыгын сатуны туктатуны тәкъдим итәргә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына һәм «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларыннан рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков